**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 16.12.2020** **№ 941**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу Тәртибен раслау турында**

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Законны үтәү йөзеннән һәм Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу, Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче барлык гражданнарның һәр дәрәҗәдәге гомуми белем алуга хокукларын тәэмин итү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу Тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (Әхмәтҗанов Н.К.) мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу эшен оештырырга.
3. Балаларны исәпкә алуны үткәрүдә катнашучы барлык органнар, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә үз вәкаләтләре кысаларында «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ һәм мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алуны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә .
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә..

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
Расланды
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 декабрендәге 941 нче номерлы Карары белән

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу
Тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) билгеләгән мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу Тәртибе (алга таба тексты буенча Тәртип) Россия Федерациясе Конституциясе, 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында», 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында», 2003 елның 24 сентябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси белешмәләр турында», 2006 елның 27 июнендәге 149-ФЗ номерлы «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында», 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль Законнары, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Биектау муниципаль районының башка норматив хокукый актлары нигезендә эшләнде.

1.2. Тәртип Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче, ата-аналары (законлы вәкилләре) билгеләгән мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алуны муниципаль мәгариф учреждениеләре һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә балаларны исәпкә алуны үткәрүдә катнашучы оешмалары белән оештыруны билгели.

1.3. Ел саен мәҗбүри исәпкә барлык туганнан алып 18 яшькәчә балалар, шулай ук гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы 18 яшьтән өлкәнрәк затлар, муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче (даими яисә вакытлыча) яки яшәү (тору) урыны буенча теркәлүе булуга (булмауга) бәйсез, белем алуга конституцион хоукны тәэмин итү максатларында, алынырга тиеш.

1.4. Тәртип түбәндәге максатларда эшләнгән:

- федераль дәүләт белем бирү стандартлары чикләрендә һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

- Биектау муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең төп белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында белем алырга тиешле балаларны үз вакытында исәпкә алуны оештыру.

1.5. Муниципаль мәгариф учреждениеләренең балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләре һәм органнары белән үзара эшчәнлеген балаларны исәпкә алу буенча оештыру эшен «Мәгариф бүлеге» МКУ үткәрә.

1.6. Балаларны исәпкә алу түбәндәге учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашырыла:

- Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү учреждениеләре;

- Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ;

- «Биектау үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;

- Биектау муниципаль районында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге;

- Биектау муниципаль районы башкарма комитеты балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе;

- Биектау районы буенча Россия ЭЭМ бүлекчәсенең полиция һәм юл хәрәкәте иминлеге бүлеге;

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге;

- Биектау муниципаль районы авыл җирлекләре администрацияләре һәм башкарма комитетлары (үз компетенциясе чикләрендә).

1.7. Әлеге Нигезләмә нигезендә җыела торган балаларны исәпкә алу мәгълүматы "Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аның конфиденциальлеген тәэмин итә торган тәртиптә җыелырга, тапшырылырга, сакланырга һәм кулланылырга тиеш.

.

## 2. Исәпләү мәгълүматларын формалаштыру

2.1. Муниципаль берәмлек территориясендә балаларны исәпкә алу «Мәгариф бүлеге» МКУ төзи торган белешмәләрнең бердәм мәгълүмат базасын булдыру һәм алып бару юлы белән башкарыла.

Исәпкә алынырга тиешле балалар турында мәгълүматлар базасын формалаштырганда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрдән алына торган мәгълүмат кулланыла:

- Муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре (алга таба - МБДОУ);

Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре (алга таба - МБОУ);

- “Биектау үзәк район хастаханәсе” ДАССУ;

- Биектау муниципаль районындагы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге;

- Биектау муниципаль районы башкарма комитеты балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе;

- Биектау районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының участок полиция һәм юл хәрәкәте иминлеге бүлеге;

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге;

2.3. Мәгълүматлар базасын формалаштыру чыганаклары булып түбәндәгеләр хезмәт итә:

2.3.1. Балалар турында гомуми белем бирү учреждениеләре мәгълүматлары:

- әлеге мәгариф учреждениесендә аларның яшәү урынына бәйсез рәвештә укучылар;

- сәламәтлеге торышы буенча белем алмаган кешеләр;

- Биектау муниципаль районы территориясеннән читтә сәламәтлек саклау учреждениеләрендә вакытлыча белем алучыларны;

- закон бозып гомуми белеме булмаган һәм белем алмаган (мөһим булмаган сәбәпләр аркасында дәресләргә йөрмәүче);

-6 яшь 6 айга җиткән мәктәпкәчә белем учреждениеләренә йөрми торган балалар турында;;

- гомумбелем бирү оешмасына беркетелгән территориядә яшәүче һәм башка гомуми белем бирү оешмаларында, шул исәптән махсуслашкан оешмаларда укучыларны.

2.3.2. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең балаларга йөрүче балалар һәм агымдагы елда мәктәпкәчә белем алуны тәмамлаучы һәм якынлашып килүче уку елында беренче сыйныфка укырга кабул ителергә тиешле балалар турында мәгълүматлар.

2.3.3. Муниципаль сәламәтлек саклау учреждениесенең участок педиатрлары һәм фельдшерларының балалар халкы турында, шул исәптән торак урыны буенча теркәлмәгән, әмма тиешле территориядә фактта яшәүче балалар турында белешмәләре.

2.3.4. Опека һәм попечительлек органы, социаль яклау органнары белгечләреннән муниципаль берәмлек территориясенең торак секторын тикшерү нәтиҗәсендә алынган балалар турындагы белешмәләр, шул исәптән яшәү урыны буенча теркәлмәгән, әмма асылда тиешле территориядә яшәүче һәм закон бозып белем алмаган балалар турындагы белешмәләр.

2.3.6. Биектау районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының участок вәкаләтле полициясе һәм ПДН бүлегеннән муниципаль берәмлек территориясенең торак секторын тикшерү нәтиҗәсендә алынган балалар турындагы белешмәләр, шул исәптән яшәү урыны буенча теркәлмәгән, әмма асылда тиешле территориядә яшәүче һәм закон бозып укымаучы балалар турында,.

2.3.7. Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары администрацияләреннән алынган, әлеге территориядә теркәлгән һәм (яисә) яшәүче, 0 яшьтән 18 яшькәчә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү

программалары буенча укырга тиешле, әмма белем алмый торган балалар турында мәгълүмат.

## 3. Балаларны исәпкә алу эшен оештыру

3.1. Биектау муниципаль районының “Мәгариф бүлеге” МКУ:

3.1.1. Мәгариф оешмаларында балаларны исәпкә алу буенча эш белән оештыру һәм методик җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра.

3.1.2. Белем бирү оешмаларыннан гомуми белем бирү оешмаларына кабул ителә торган балалар саны турында, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алмаучы балалар турында, дәресләргә килмәүче яисә даими рәвештә сәбәпсез дәрес калдыручы, гомуми белем бирү учреждениеләренә кабул ителә торган яисә уку елы дәвамында һәм җәйге чорда алардан китүче балалар турында белешмәләр соратып ала.

3.1.3. Мәктәпкәчә балалар учреждениеләренә йөрми торган 6 яшь 6 айга җиткән балалар турында һәм муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларның гомуми белем бирү учреждениеләренә кабул ителүе турында мәгълүматлар формалаштыра.

3.1.4. Учреждениеләрдән, оешмалардан һәм гражданнардан, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алмаган, дәресләргә йөрми торган яки сәбәпсез дәрес калдыручы балалар турында белешмәләр кабул итә

3.1.5. Әлеге мәгълүматны анализлый, муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче балалар турында мәгълүматлар базасын формалаштыра.

3.1.6. Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алмаган балаларны «Мәгариф бүлеге» МКУ карамагындагы гомуми белем бирү учреждениеләренә укытуга урнаштыру чаралары күрә.

3.2. Гомуми белем бирү оешмалары:

3.2.1. 0 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларны, шулай ук гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы 18 яшьтән өлкәнрәк затларны, шул ук вакытта балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре белән үзара эш итеп, гомуми белем бирү оешмасы беркетелгән территориядә яшәүче затларны исәпкә алу эшен оештыралар
.

3.2.2. Ел саен 20 сентябрьгә кадәр “Мәгариф бүлеге” МКУнда 0 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар, шулай ук гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы, гомуми белем бирү оешмасы беркетелгән территориядә яшәүче 18 яшьтән өлкәнрәк затларны (1,2 нче кушымта) исемлекләрен бирәләр.

3.2.3. Үз оешмаларында укучыларның яшәү урынына карамыйча агымдагы исәбен оештыралар, гамәлгә ашыралар. Укучылар контингенты һәм аларның хәрәкәте турында гомуми мәгълүматлар гомуми белем бирү оешмасында чиреккә 1 тапкыр рәсмиләштерелә һәм җәйге чорда «Мәгариф бүлеге» МКУына (3,4 нче кушымта) бирелә.

3.2.4. Дәресләргә йөрүдә, үз-үзен тотышында, укытуда, үсештә һәм сукбайлыкка тартылучы социаль адаптациядә проблемалары булган укучыларга системалы контроль гамәлгә ашырыла.

3.2.5. Социаль куркыныч хәлдә булган, шулай ук йөрмәүче яисә системалы рәвештә сәбәпсез дәресләр калдыручы балигъ булмаган балаларны ачыклыйлар (хисап чоры өчен уку сәгатьләренең 1/3 нән артыгын). Аларны тәрбияләү һәм гомуми белем алуы буенча чаралар күрә.

3.2.6 Сәбәпсез дәресләргә йөрмәгән (5-нче кушымта) балигъ булмаганнарны исәпкә алу карталарын рәсмиләштерәләр.

3.2.7. Агымдагы айның 20 числосына кадәр "Мәгариф бүлеге" МКУ һәм балигъ булмаганнар эше буенча һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә укуны туктаткан, дәресләргә йөрмәүче яки системалы рәвештә сәбәпсез дәрес калдыручы балалар турында хәбәр итәләр.

3.2.8 Гомуми белем бирү оешмасына укырга балаларны кабул итү Тәртибе нигезендә балалар исәпкә алу эше барышында ачыкланган гомуми белем алмаучы, балаларны укуга кабул итәләр.

3.2.9. Балалары белем алуга комачаулаган һәм (яисә) үз балаларын тәрбияләү һәм укыту бурычларын тиешенчә үтәмәгән гаиләләр ачыкланган очракта:

-балигъ булмаганнарны укытуны оештыру өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) белән кичекмәстән үзара хезмәттәшлек чаралары күреләә;

- бу хакта Биектау муниципаль районы буенча ЭЭБ балигъ булмаганнар бүлекчәсенә һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район комиссиясенә гамәлдәге законнар нигезендә йогынты ясау чараларын күрү өчен хәбәр итә;

- Ачыкланган балалар һәм аларны укытуны оештыру буенча күрелгән чаралар турында "Мәгариф бүлеге" МКУсына мәгълүмат бирәләр.

3.3. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары ел саен 20 гыйнварга кадәр гомуми белем бирү оешмаларына тапшыралар:

- агымдагы елда мәктәпкәчә белем алуны төгәлләүче һәм беренче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар турында белешмәләр.

- балалар бакчасына йөрми торган һәм беренче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар турындагы белешмәләр (6 нчы кушымта)

3.4. "Мәгариф бүлеге" МКУ ел саен 1 сентябрьгә кадәр "Биектау үзәк район хастаханәсе" ДАССУ белән инвалид балалар исемлекләрен (№7 Кушымта) килештерә.

3.5. Территориаль берәмлекнең балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау органнары һәм системалары «Мәгариф бүлеге» МКУга мәҗбүри укытылырга тиешле, әмма гомуми белем алмаучы балалар турында мәгълүмат җибәрә.

3.6. Нинди дә булса сәбәпләр аркасында гомуми белем алмаган балалар турында булган мәгълүмат нигезендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре белән кызыксынган затлар белән берлектә гамәлдәге законнар нигезендә тиешле чаралар күреләә.

## 4. Белем алу формаларын исәпкә алу

4.1. Төп гомуми белем алганнан һәм унсигез яшькә җиткәннән соң, укучылар, шулай ук укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) бала фикерен исәпкә алып төп гомуми белем алуын тәмамлаганчы, белем алу формаларын сайларга хокуклы.

4.2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” МКУ балигъ булмаган укучыларның, унсигез яше тулган укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) билгеләгән белем алу формаларын исәпкә ала. (8 нче кушымта)

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу Тәртибенә

**ТР Биектау муниципаль районы**

**__________**

**МБОУ беркетелгән территориядә яшәүче балаларны исәпкә алу турында белешмәләр**
**(авылының, …,…,…,…) 0 дән 18 яшькәчә**

| яше / авылы | 0 | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | Шуларның 7дән18 яшькәчә укубелән колачланмаганнары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Мәктәп директоры: имза Ф.И.О
Авыл җирлеге Башлыгы: имза Ф.И.О

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу Тәртибенә

**ТР Биектау муниципаль районы ________ МБОУ беркетелгән территориядә яшәүче балалар исемлеге (авыл, )**
**0 дән 18 яшькәчә**

| № | Баланың ФИО тулысынча (алфавит тәртибендә туган еллары буенча) | Туу датасы | Адресы | | Мәктәпкәчә яшьтәге балалар | | Кайда укый, эшли (класс, мәктәп; ССУЗ, ВУЗ…) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Теркәү урыны буенча | Фактта яшәү урыны (торуы) | Кайда тәрбияләнә (әгәр ДОУ га йөрмәсә) | ДОУ га йөрү турында мәгълүматлар, ДОУ исемен күрсәтеп | | |

Директор школы: подпись Ф.И.О
Глава сельского поселения: подпись Ф.И.О
М.П.

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә
яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем
бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу
Тәртибенә

**Белем бирүче оешмада укучыларның исемлеге**

______________________________________
**(белем бирү оешмасының исеме)**

| **№ т/б** | **Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Туу датасы** | **Класс** | **Адрес** | | **Искәрмә** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Теркәлү буенча | Фактта яшәве (торуы) | |

Белем бирү оешмасы җитәкчесе ____________ ____________________
имза Ф.И.О

5 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә
яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми
белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә
алу Тәртибенә

**_________ уку елының_____ аена дәресләргә йөрмәүче яки системалы рәвештә сәбәпсез калдыручы балалар турында мәгълүмат**

**________________________________**
**(белешмә җибәрүче белем бирү оешмасы исеме)**

| № т/б | Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме | Мәктәп, класс | Калдырылган дәресләр саны | Калдыру сәбәбе | Ата-анасының Ф.И.О | Балигъ булмаганга карата күрелгән чаралар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Белем бирү оешмасы җитәкчесе ___________ _________________
имза Ф.И.О

6 нчы кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә
яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми
белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу
Тәртибенә

**Биектау муниципаль районы ________ МБОУ беркетелгән территориядә теркәлгән һәм (яки) яшәүче һәм якынлашучы уку елында беренче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар турында мәгълүматлар**

| № т/б | Ф.И.О. тулысынча | Туу датасы | Теркәлү адресы | Яшәү адресы | Кайсы мәктәпкә планлаштыралар |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Белем бирү оешмасы җитәкчесе ___________ __________________
имза Ф.И.О

7 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә
яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми
белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу
Тәртибенә

**Биектау муниципаль районы буенча ________20 ______елга 18 яшькә кадәрле инвалид балалар исемлеге**

| № т/б | Ф.И.О. тулы сынча | Туу Датасы | Яшәү адресы | Диагноз | Кайсы белем бирү оешмасына йөри | Укыту программасы (төп, адаптация ләнгән) | Белем алу формасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |

8 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә
яшәүче мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми
белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә
алу Тәртибенә

**Балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан гаилә белеме һәм үзлегеңнән белем алу рәвешендә белем алу формасын сайлавы турында мәгълүмат**

| № | Баланың ФИО /туу датасы /класс | Ата-анасы(закон.вәкиле) / гариза бирү датасы | Яшәү урыны/телефоны | Белем бирү оешмасы (арадаш яки ДЙА) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |